**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 11 декабреннән № 15

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән, Менделеевск муниципаль районы «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ**:

1. Менделеевск муниципаль районының 2015 елның 30 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Нигезләмәнең 24 статьясындагы 24.3 пунктында 4 пунктчасында "хезмәт кенәгәсен" сүзләреннән соң һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр " сүзләрен өстәргә.

б) 2) 29 статьясындагы 29.1 пунктның 4 пунктчасын "(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Кузнецову Т.П. йөкләргә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге
Советы Рәисе: Т.П.Кузнецова.